ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2024 с.Старое Дрожжаное № 121

Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының 2024 елның 07 мартындагы 02-08-02-2024 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Спорт судьясының квалификация категориясен бирү һәм спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июнендәге 259 номерлы карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 2.4.1 пункты** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Спорт разряды бирү өчен документларны карау вакыты теркәлгән көннән алып 16 эш көне тәшкил итә.

Спорт разрядын бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итү спорт разряды бирү өчен документлар карау тәмамланган көннән алып 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

**2) 2.5.1 пунктында:**

**«б» пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) кул куйган судьялар коллегиясенең составы һәм квалификациясе турында белешмә күчермәсе;»;

**«г» пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) спортчының физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмага каравын раслый торган документның күчермәсе (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе гамәлдә булу туктатылган очракта яисә исемлеккә кертелгән физкультура-спорт оешмасының спорт разрядын бирү өчен документлар бирелгән очракта);»;

**«д» пунктчасына** түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Документлар электрон рәвештә тапшырылганда шәхесне таныклый торган документтан белешмәләр тиешле кырларга интерактив порталь формада кертелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып запрос җибәрү юлы белән тикшереләчәк. 14 яшькә җитмәгән затлар өчен - туу турында таныклык күчермәсе.

Документлар электрон формада бирелгәндә туу турында таныклыктан белешмәләр тиешле кырларга интерактив порталь формада кертелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып запрос җибәрү юлы белән тикшереләчәк.

Әгәр туу турында таныклык чит телдә бирелгән булса, аның төп нөсхәсен һәм нотариаль рәвештә расланган тәрҗемәсен тәкъдим итәргә кирәк.

Документларны электрон формада тапшырганда, нотариус ЭП имзалаган нотариаль расланган тәрҗемә бирелә.

Хәрби хезмәткә чакырылу буенча хәрби хезмәтне үтүче хәрбиләр тарафыннан Россия Федерациясе гражданы паспорты битләренең күрсәтелгән күчермәләре урынына хәрби билет күчермәсе тәкъдим ителергә мөмкин;»;

**«е» пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) спорт разряды бирү өчен спортчы аларны үтәү нормаларын, таләпләрен һәм шартларын үтәгән физкультура чарасы һәм (яки) спорт ярышлары турында нигезләмәнең (регламентның) күчермәсе;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.И. Мөхәммәтҗанов